ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2020 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлегенең Кәкре Күл авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

2019 елның 24 ноябре № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Кәкре Күл авыл җирлеге Кәкре Күл авылында гражданнар җыены нигезендә

Карар:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлегенең Кәкре Күл авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, (I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының һәм көндезге бүлектә белем алучы студентлар) 500 сум күләмендә үзсалым кертергә

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру

Кәкре Күл авылында урамнарны яктыртуны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу.

Кривоозерка авылында кырларны чабу эшләре.

- Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру;

Кәкре Күл авылындагы тирән насосны, сүүткәргечне ремонтлау һәм алыштыру

Кәкре Күл авылындагы шахта коеларын төзекләндерү.

- Каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу;;

контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү, Кәкре Күл авылы контейнерлары сатып алу.

- Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

Кәкре Күл авылы Школьная, Горький, Пушкин, Терешкова, Гагарин урамнары, Демьян ярлы 1й тыкрыгы, Демьян ярлы 2й тыкрыгы, Париж Коммунасы урамнары ком һәм вак таш өю (ЩПС).

кышкы чорда Кәкре Күл авылында автомобиль юлларын карап тоту.

3 Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә. Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

Кәкре Күл авыл җирлеге башлыгы
ТР Аксубай муниципаль районы С.С. Елисеев